ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Школьная, д.17,

с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ

РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 17йорт,

Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

№ 22 06.12.2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2006 елның 1 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының «Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен» раслау һәм аларны гамәлгә кертү турында»гы 1 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина